# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлегенең Каенсар авылы торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 23 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенең Каенсар авылы торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1.2025 елда Каенсар авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә. Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлегенең Каенсар авылында 1 төркем инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк кешеләр, эшкә сәләтсез гражданнар, үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә сәләтсез гражданнар, армия сафларында срочная хезмәт узучы затлар, ялгыз аналар, гаилә, балигъ булмаган балалары булган, социаль куркыныч хәлдә булган, теркәлгән, әмма яшәмәүче затлардан тыш яшәү урыны буенча Бөек Ватан сугышы тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, үзара салым суммасының 90% күләмендә ташлама билгеләнгән Россия Федерациясе Кораллы көчләрендәге контракт буенча хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзалары; үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән көндезге формада белем алучы студентлар.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

2) ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. baltasi.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Муниципаль берәмлек башлыгы,Совет Рәисе А.А.ХӨСНЕТДИНОВ